ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТУКАЙ МУНИЦПАЛЬ РАЙОНЫ
МУСАБАЙ-ЗАВОД АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

# КАРАР

“13” октябрь 2023 ел    Мусабай-Завод авылы    № 20

**“Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Мусабай-Завод авыл җирлегенең Кызыл-Байрак авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында”**

“Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Тукай муниципаль районы “Мусабай-Завод авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставының нигезендә

**КАРАР БИРӘМ:**

1. Тукай муниципаль районы Мусабай-Завод авыл җирлегенең Кызыл-Байрак авылында 2023 елның 27 октябрендә 14.00 сәгатькә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены билгеләргә.
2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

“Мусабай-Завод авыл җирлегенең Кызыл-Байрак авылы территориясендә 2024 елда балигъ булган, Мусабай-Завод авыл җирлегенең Кызыл-Байрак авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр кешегә 500 (биш йөз) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм I һәм II группа инвалидларга һәм Бөек Ватан сугышы ветераннарына, ялгыз карт гражданнарга һәм кендезге формада укучы студентларга, күп балалы гаиләләргә бер тапкыр түләүне киметергә һәм аны әлеге категория гражданнар өчен 250 (ике йөз илле) сум күләмендә билгеләргә, аларның суммасы түбәндәге мәсьәләләрне:
-юллар салу эшләрен башкару, юлларны ремонтлау, вак таш һәм асфальт валчыклар сатып алу, махсус техника хезмәтләре күрсәтү;
- урам утларын ремонтлауны хәл итүгә юнәлдерүгә килешәсезме

“ӘЙЕ”    “ЮК”.

3. Татарстан Республикасы, Тукай районы, Кызыл-Байрак авылы, Үзәк урамы, 7б йорт адресы буенча гражданнар җыенын үткәрергә.
4. Тукай муниципаль районы Мусабай-Завод авыл җирлеге башкарма комитетын Гражданнар җыенын оештыручы итеп билгеләргә.
5. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә.
6. Әлеге карарны Тукай муниципаль районының рәсми сайтында “авыл җирлекләре” бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга.
7. Әлеге карар халыкка җиткерелгән көннән үз көченә керә.

Мусабай-Завод
авыл җирлеге Башлыгы    З.З. Хөсәинова